**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР №__2__

Урыссу штб 31.01.2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Ютазы район Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кабул иткән очракта:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы Карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-

60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: Пушкин урамы, 38 йорт; Урыссу урамы, 60 йорт; Урыссу урамы, 1Б йорт.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы А.Ә. Шәфигуллин